## МОНОЛОГИК СӨЙЛӘМГӘ ӨЙРӘТҮ

**Бирем**

Үзегез белән таныштырыгыз. Сөйләмегездә түбәндәге мәгълүматлар да булсын:
— укуыгыз һәм сыйныфташларыгыз;
— буш вакытыгызны үткәрү һәм мавыгуларыгыз;
— якын туганнарыгыз һәм аларның һөнәрләре.

### Үзем турында

Минем исемем — ... . Миңа ... яшь. Мин — укучы. Хәзерге вакытта ... (*Казан, Бөгелмә, Әлмәт* һ. б.) шәһәренең ... нчы/нче мәктәбендә ... нчы/нче сыйныфта укыйм. Сыйныфыбыз бик тату. Сыйныфта без ... укучы. Сыйныфташларым — тырыш, тәртипле, ярдәмчел укучылар.

Мин ... шәһәрендә / авылында, ... урамында, ... нчы/нче йортта, ... нчы/нче фатирда яшим.

Мин ... (*тарих, әдәбият, телләр, рәсем, спорт, музыка, сәнгать*) белән кызыксынам. Мин ... (*русча, татарча, инглизчә, французча, алманча, төрекчә, испанча, гарәпчә*) беләм.

Буш вакытымда ... (*музыка тыңларга, китаплар укырга, спорт белән шөгыльләнергә, компьютерда уйнарга*) яратам.

Гаиләбездә ... (*ике, өч, дүрт, биш*) кеше: әтием, әнием, ... (*абыем, апам, энем, сеңлем*) һәм мин. Әниемнең исеме — ... . Ул — ... (*укытучы, тәрбияче, хисапчы, табибә, хуҗабикә*). Әтиемнең исеме – ... . Ул — ... (*эшмәкәр, эшче, төзүче, табиб, тәрҗемәче*). Абыемның (*апамның, энемнең, сеңлемнең*) исеме — ... . Ул — ... (*укучы, студент, аспирант*). Гаиләбез бик тату.

Безнең туганнарыбыз күп. Алар ... (*Казанда, Яр Чаллыда, Мәскәүдә, Алабугада, Санкт-Петербургта, Пермьдә, Ульяновскида, Саратовта*) яшиләр.

? Мәктәптә Сезгә кайсы фән күбрәк ошый һәм ни өчен?
Сез татар телен ничә ел өйрәнәсез?
Туганнарыгыз белән еш очрашасызмы?

**Бирем**

Дусларыгыз белән таныштырыгыз. Сөйләмегездә түбәндәге мәгълүматлар да булсын:
— якын дусларыгызның исемнәре;
— аларның укулары һәм хыяллары;
— дусларыгыз белән ничек танышуыгыз.

## Дусларым турында

Минем өч дустым бар. Берсе — Азат, икенчесе — Денис, өченчесе — Алсу. Алар өчесе дә — минем сыйныфташларым. Без — беренче сыйныфтан бирле дуслар. Без мәктәпкә әзерлек сыйныфларында танышкан идек һәм хәзер һәрвакыт мәктәпкә бергә барабыз, мәктәптән дә бергә кайтабыз. Кичләрен дә бергә саф һавада йөрибез. Ял көннәрендә паркка, кафеларга барабыз.

Азат математика дәресләрен бик ярата. Ул «дүрт»ле-«биш»ле билгеләренә генә укый, төрле олимпиадаларда катнаша. Аның хәтта берничә Мактау грамотасы һәм дипломы бар. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Азат программист булырга хыяллана.

Денис тарих белән кызыксына. Ул бик күп укый, шуңа күрә күп белә. Денисның тарихчы буласы, археологик экспедицияләрдә катнашасы килә. Аның әтисе дә — тарихчы, университет профессоры. Аларның өендә дөнья тарихы, Россия тарихы буенча китаплар, кызыклы энциклопедияләр бик күп.

Алсу чит телләрне яхшы белә. Ул туган телендә, инглиз телендә бик яхшы сөйләшә, тагын испан теле белән дә кызыксына. Алсуның иң зур хыялы — тәрҗемәче булу. Аның төрле илләрдә буласы, төрле халыкларның мәдәниятләрен өйрәнәсе килә.

Дусларым бик ярдәмчел, юмарт, максатчан. Мин аларны бик яратам. Алар белән аралашу бик күңелле.

? Сезгә дусларыгызның нинди сыйфатлары ошый?
Сез алар белән ничә ел дус?
Дуслык турында мәкальләр беләсезме?

**Бирем**

Мәктәбегез турында сөйләгез. Сөйләмегездә түбәндәге мәгълүматлар да булсын:

— мәктәптәге уку кабинетлары;
— мәктәп укучыларының уңышлары;
— мәктәп китапханәсе.

## Мәктәбем турында

Мин укый торган мәктәп яңа. Ул дүрт катлы, зур һәм бик матур.

Беренче катта ашханә, китапханә, актлар залы, спорт залы урнашкан. Икенче, өченче, дүртенче катларда — сыйныф бүлмәләре. Алар якты һәм уңайлы. Коридорлар иркен, тәрәзәләр биек. Коридорларда гөлләр үсә, ял итү өчен, утыргычлар куелган.

Мәктәптә бер меңнән артык укучы укый. Укулар бер сменада бара. Мәктәптә төрле кабинетлар күп: рус теле һәм әдәбияты кабинеты, татар теле һәм әдәбияты кабинеты, математика, биология, физика, химия, география кабинетлары. Алар барысы да заманча җиһазландырылган.

Мәктәпнең спорт залы зур, матур. Анда физкультура дәресләре үтә. Залда укучылар волейбол, баскетбол уйныйлар. Безнең мәктәп укучылары ел саен төрле спорт ярышларында катнашалар һәм җиңү яулыйлар. Сыйныфташларыбыз арасында мәктәп чемпионнары да бар: иң яхшы теннисчы һәм иң яхшы чаңгычы.

Мәктәбебездә төрле түгәрәкләр эшләп килә: шахмат түгәрәге, математика түгәрәге, хор түгәрәге, гимнастика түгәрәге һәм башкалар.

Мәктәп китапханәсе бик бай. Без анда бик теләп йөрибез. Уку залында төрле кызыклы журналлар укыйбыз. Китапханәдә татарча китаплар да күп. Алар безгә татар телен өйрәнү өчен бик кирәк. Шул китаплардан файдаланып, без татар теле дәресләренә презентацияләр әзерлибез, проектлар төзибез, белемнәребезне арттырырга тырышабыз.

Мин мәктәбемне бик яратам.

?

Мәктәбегездә кайсы фәннәрне өйрәнүгә аерым игътибар бирелә?
Мәктәбегездә нинди кызыклы чаралар үткәрелә?
Мәктәпне икенче өй дип атарга мөмкинме?

**Бирем**

Үзегез яшәгән йорт һәм фатирны тасвирлагыз. Сөйләмегездә түбәндәге мәгълүматлар да булсын:
— фатирыгыздагы бүлмәләр;
— төрле бүлмәләрдәге җиһазлар;
— фатирыгызның сезгә ошавы-ошамавы.

## Йортыбыз, фатирыбыз

Безнең йортыбыз ... урамында урнашкан. Бу — ... (*биш, тугыз, унике*) катлы ... (*иске, яңа*) йорт. Фатирыбыз ... (*алтынчы, унынчы*) катта урнашкан. Ул ... (*бер, ике, өч*) бүлмәле. Анда алгы бүлмә, аш бүлмәсе, кунак бүлмәсе, йокы бүлмәсе, балалар бүлмәсе, эш бүлмәсе, юыну бүлмәсе бар.

Алгы бүлмә кечкенә. Анда көзге, кием шкафы, аяк киеме киштәсе бар. Идәндә кечкенә палас ята. Аш бүлмәсе зур, якты һәм уңайлы. Анда аш өстәле, урындыклар, савыт-саба шкафы, газ плитәсе, суыткыч бар. Тәрәзәгә матур пәрдә эленгән. Тәрәзә төбендә гөлләр үсә.

Кунак бүлмәсендә журнал өстәле, диван, ике кәнәфи, китап шкафы тора. Идәнгә зур һәм йомшак келәм җәелгән. Диварга сәгать эленгән. Бу бүлмә бик иркен, бик матур.

Йокы бүлмәсендә җиһазлар күп түгел. Анда карават, кием шкафы, көзге һәм китап киштәләре бар.

Балалар бүлмәсендә карават, язу өстәле, урындык, китап шкафы бар. Язу өстәлендә компьютер һәм өстәл лампасы тора. Китап шкафында русча, татарча китаплар, төрле сүзлекләр, энциклопедияләр күп. Диварга фотолар һәм календарь эленгән.

Юыну бүлмәсендә көзге, юыну әйберләре киштәсе, кер юу машинасы бар.

Фатирыбыз миңа бик ошый.

?
Сез яши торган йорт янында нәрсәләр бар?
Сез бу йортта ничә ел яшисез?
Фатирыгыздагы җиһазларны яңартырга телисезме?

**Бирем**

Ел фасыллары турында сөйләгез. Сөйләмегездә түбәндәге мәгълүматлар да булсын:
— һәр ел фасылының матурлыгы;
— укучыларның җәйге каникулны үткәрүе;
— яраткан ел фасылыгыз.

## Ел фасыллары

Дүрт ел фасылы бар: кыш, яз, җәй, көз.

Кышын көннәр салкын була. Урамнарны кар күмә. Елгаларны боз каплый. Кышын балалар чана, чаңгы, тимераякта шуарга яраталар. Алар кар бабай ясыйлар, хоккей уйныйлар. Укучыларның, студентларның кышкы каникулы була. Алар күңелле ял итәләр.

Кыштан соң яз килә. Язгы көннәр җылы, кояшлы була. Урамнарда кар эри, гөрләвекләр ага. Кайвакыт яңгырлар ява, күк күкри. Язын табигать матурлана. Җылы яклардан кошлар кайта. Урманнарда беренче чәчәкләр күренә.

Яздан соң җәй килә. Җәен көннәр эссе, аяз була. Җәй — ял вакыты. Укучыларның, студентларның каникулы башлана. Алар спорт лагерьларында ял итәләр, башка шәһәрләргә, илләргә баралар. Җәен су керәләр, кояшта кызыналар, көймәдә йөриләр, волейбол, футбол уйныйлар.

Җәйдән соң көз килә. Көзен көннәр болытлы, яңгырлы була. Кошлар җылы якларга китәләр. Бакчаларда, кырларда уңыш җыялар. Көзен мәктәпләрдә, училищеларда, техникумнарда, университетларда укулар башлана. Мин ... (*җәйне, көзне, кышны, язны*) яратам.

?

Сезнеңчә, ни өчен күп кеше җәйне ярата?
Кышкы һәм җәйге каникуллар Россиядә күпме дәвам итә?
Язгы көннәр көзге көннәрдән аерыламы?

**Бирем**

Яраткан бәйрәмнәрегез турында сөйләгез. Сөйләмегездә түбәндәге мәгълүматлар да булсын:
— күпчелек кешеләрнең иң яраткан бәйрәме;
— Яңа елны каршылау;
— хатын-кызларны һәм ир-атларны котлау.

## Россиядә һәм Татарстанда бәйрәмнәр

Безнең илдә иң яраткан бәйрәмнәрнең берсе булып Яңа ел бәйрәме санала. Бу бәйрәмгә алдан ук әзерләнә башлыйлар: дусларга һәм туганнарга бүләкләр сатып алалар, чыршы бизиләр. Яңа ел — гаилә бәйрәме. 31 нче декабрь көнне төнге сәгать уникедә бөтен гаилә бәйрәм табынына җыела. Барысы да бер-берсен Яңа ел белән котлыйлар, бәхет телиләр. Ә ан-